Шәһәр күләмендә география фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
8 нче сыйныф

Эш вакыты – 90 минут
Гомуми балл – 80

1. Баренц белән Лаптев диңгезләре арасында нинди диңгез урнашкан?
(2 балл)

а) Балтыйк; б) Карск; в) Көнчыгыш Себер; г) Беринг

2. Циклоннар якынча нинди тизлек белән хәрәкәт итәләр? (2 балл)

а) 10 км/сәг.; б) 20 км/ сәг.; в) 30 км/ сәг.; г) 40 км/ сәг.

3. Кыш сезонында антициклональ һава торышы Россиянең кайсы өлкәләренә хас? (4 балл, берничә җавап булырга мөмкин)

а) Хибин тавы; б) Көнчыгыш Себер; в) Балтыйк диңгезе;
г) Рус тигезлегенең көньягы; д) Азов диңгезе

4. Урынның планнын географик кооррдинаталар ачыклау өчен кулланып буламы? (2 балл)

а) булмый; б) була; в) план кечкенә булырга тиеш; г) линейка ярдәмендә була

5. С.И. Дежневных Себер һәм Ерак Көнчыгышны өйрәнү елларын дөрес итеп билгеләгез. (2 балл)

а) 1539 –1562 гг.; б) 1640 –1668 гг.; в) 1732 –1743 гг.; г) 1814 –1819 гг.

6. 60 º паралельның 1º озынлыгы километрларда: (2 балл)

а) 104,6 км.; б) 85,4 км.; в) 55,8 км.; г) 19,4 км.

7. Россиянең иң сазлыклы өлкәсен сайлап алыгыз (2 балл)

а) Рус тегезлеге; б) Ерак көнчыгыш; в) Көнбатыш Себер тигезлеге;

г) Кола ярымутравы; д) Бөгелмә яссы таулыгы

8. Нинди нефть чыганагы юк? (2 балл)

а) Дорогобуж; б) Самотлор; в) Лянтор; г) Шаим

9. Җәй вакытында циклон Россиянең кайсы өлкәләрендә өстенлек итә?

(4 балл, берничә җавап булырга мөмкин)

а) Каспий диңгезендә;

б) Рус тигезлегенең көнбатышында;

в) Көнчыгыш Себердә;

г) Ерак Көнчыгышта

10. Арктикада урнашкан тауларда кар чиге ничә метрдан башлана? (2 балл)

а) 4000 м; б) 3000 м; в) 2000 м; г) 1000 м; д) 100 м.

11. Кайсы тау токымы үзенең төренә туры килә? (2 балл)

а) мрамор-утырма; б) гранит-метоморфик;

в) базальт-метаморфик; г) известьташ-утырма

12. Декан яссы таулыгы Азиянең кайсы өлешендә урнашкан? (2 балл)

а) төньяк; б) көньяк; в) көнбатыш; г) көнчыгыш

13. Көньяк Америкада нинди табигый зона юк? (2 балл)

а) саванналар; б) чүлләр; в) далалар; г) урман тундра

14. Россия кайсы ил белән су юлы аша чиктәш? (2 балл)

а) Швеция; б) Молдавия; в) Әфганстан; г) Япония

15. Төньяк Америкада нинди табигый зона юк? (2 балл)

а) тундралар; б) тайга; в) чълләр; г) экваториаль урманнар

16. Кояш системасындагы планеталар арасында үз күчәре тирәсендә иң тиз әйләнүче планетаны табыгыз (2 балл)

а) Меркурий; б) Жир; в) Юпитер; г) Уран; д) Нептун.

17.Бирелгән елгаларның кайсы диңгез бассейнына коюын ачыкларга

(8 балл)

Елга исеме	**Диңгез исеме**
Идел	
Обь	
Амур	
Лена	
Колыма	
Дон	
Днепр	
Урал	

18. Россия территориясендә була торган җил белән бәйле куркыныч һава торышы күренешләрен атагыз һәм сүрәтләгез. Барлыкка килү үзәкләрен санап чыгыгыз (12 балл).

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

19. Россиянең кайсы шәһәрләре атамаларында үз тирәләрендә тоз табылуы турында сөйлиләр? (10 балл)

20.Ике самолёт бер үк вакытта күккә күтәрелгән. Аларның беренчесе – Санкт-Петербургтан, ә икенчесе Африкадагы Эдуард күле янынан күтәрелеп киткәннәр.Ике самолётның да күтәрелеп китү урыннары 30º кч.о.та. Алар бер үк тизлектә параллель юнәлештә көнчыгышка очып киткәннәр. Беренче самолёт Россиянең Магадан шәһәренә төшеп утырган. Икенчесе төшәр алдыннан, көньяккарак тайпылган һәм Яңа Гвинеяның Маклай ярына борылып төшкән.Ике очракта да төшү урыны чама белән 50 º кч.о.та урнашкан.

Ике самолётның кайсысы билгеләнгән урынга тизрәк һәм күпме вакытка тизрәк очып килгән? Ни өченике самолётның очу вакытында аерма бар? (14 балл)